**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**

## КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**№ 3** **25.10.2024 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.11.2013 ел, № 909 (29.11.2023 ел, №1532 редакциясендә) карары белән расланган үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставы белән гражданнар җыенына түбәндәге сораулар чыгарылды:

1. 2025 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- Иске Элмәле торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, агач кисү, балалар өчен ишегалды мәйданчыгын киртәләү урнаштыру, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника арендалау);

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Иске Элмәле торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Иске Элмәле торак пунктында вак таш сатып алу, урам-юл челтәрен салу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу).

**1.2. 2024 елда гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 100 000 сум акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:**

- Иске Элмәле торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, агач кисү, балалар өчен ишегалды мәйданчыгын киртәләү урнаштыру, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника арендалау);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 402 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 225 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында 225 катнашучы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

**Халык җыены карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча карар:

2.1. 2025 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- Иске Элмәле торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас

частьләр сатып алу, агач кисү, балалар өчен ишегалды мәйданчыгын киртәләү урнаштыру, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника арендалау);

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Иске Элмәле торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Иске Элмәле торак пунктында вак таш сатып алу, урам-юл челтәрен салу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу).

**1.2. 2024 елда гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 100 000 сум акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:**

- Иске Элмәле торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, агач кисү, балалар өчен ишегалды мәйданчыгын киртәләү урнаштыру, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника арендалау) – **кабул ителгән дип танырга**.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Иске Элмәле авылы, Үзәк урамы, 10. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында**
**рәислек итүче**
**Яңа Элмәле авыл**
**җирлеге башлыгы** **И.М. Җамалтдинов**